

Чынлап та шулай. Алар бергә-бергә эшли дә, ял да итә беләләр.
Шулай, Дубенка районы Ломат авылы музеенда Аналар коненә багышланган чара vткән. Тvгәрәк остәл артында хатын-кызлар гаиләләре, туган авыллары турында истәлекләрен янартканнар, бvгенге кон тормышлары, алдагы планнары белән уртаклашканнар. Авыл әниләре бергәләшеп чәй артында матур очрашу vткәргәннәр.
Шулай ук Ломат авылы музеенда авыл халкы һәм анын кунаклары очен экскурсияләр vтә. Биредә зур кызыксыну белән мәдәни мирас булып калган истәлекле әйберләрне карыйлар, якташлары Новокузнецк шәһәрендәге «Чулпан» мәчете имам-хатыйбы Анвәр хазрәт Ашировнын сонгы тапкыр нәшер ителгән «Возвращение к истокам» китабы белән дә танышалар.